ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы муниципаль районынын
Сойки
авыл жирлеге
Башкарма комитеты
Кама Тамагы районы,
Сойки авылы
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с.
Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Камско-Устьинский
муниципальный район
Исполнительный комитет
Сюкеевского
сельского поселения
Камско-Устьинский район,
с. Сюкеево
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с.
Сюкеево ул. Колхозная дом 16а


# КАРАР

**11 апрель 2019 ел** **№ 5**

2018 елның 18 декабрендәге "Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында: васыять таныклау яки ышанычнамә таныклау" Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының «нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"гы 27 номерлы Карары белән расланган нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында: васыятьнамә таныклау яки ышанычнамә таныклау"

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы Федераль закон, 2017 елның 6 июнендәге "Җирлекләрнең җирле администрацияләре башлыклары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турындагы инструкцияне раслау турында"гы Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының 97 номерлы Боерыгы нигезендә, муниципаль районнарның җирле администрацияләре башлыклары һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 декабрендәге "Нотариаль

гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 27 номерлы Карары белән расланган васыятьнамә яки ышанычнамә таныклыгын раслау турындагы нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ Регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

регламентның 2 бүлегенең 2.9 пунктының икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.

Баш тарту өчен нигез:

1) мондый гамәлләр башкару Россия Федерациясе законнарына каршы килә;

2) гамәлгә ашыру башка җирлек яки муниципаль район җирле үзидарә органының вазыйфаи заты яисә нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;

3) нотариаль гамәлләр башкару турындагы үтенеч белән эшкә яраксыз граждан яисә кирәкле вәкаләтләренә ия булмаган вәкил, яшәү урыны буенча теркәлмәгән яисә җирлектә тору урыны буенча теркәлмәгән граждан мөрәҗәгать итте;

4) дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ГМП ГМС) аша дәүләт пошлинасын һәм нотариаль тарифны түләү турында мәгълүмат кермәү;

5) мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;

6) нотариаль гамәлләр башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, Авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы Колхоз урамы, 16а йорты, китапханә бинасы;

шулай ук Хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сөйки авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: В.П. Никитин